КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 27 декабрь г.Казань № 1223

Хисап елы өчен Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен хисап чорына (үткән елга) күрсәткечләрнең ирешелгән мәгънәләре (дәрәҗәләре) һәм аларның планлаштырыла торган мәгънәләре турындагы Татарстан Республикасы Президенты доклады проектын әзерләү регламентын раслау хакында

Хисап елы өчен Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен хисап чорына (үткән елга) күрсәткечләрнең ирешелгән мәгънәләре (дәрәҗәләре) һәм аларның планлаштырыла торган мәгънәләре турындагы Татарстан Республикасы Президентының еллык доклады проектын әзерләү максатларында, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2019 елның 25 апрелендәге 193 номерлы Указын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен исәпләү методикаларын раслау турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым актлары үз көчен югалткан дип тану хакында» 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарын, Татарстан

Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының хисап елында эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү өчен ирешелгән күрсәткечләр дәрәҗәсе һәм өчъеллык чорга аларның планлаштырылучы дәрәҗәләре турында Татарстан Республикасы Президенты докладын һәм Татарстан Республикасы шәһәр округларының һәм муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген мониторинглау йомгаклары хакында Татарстан Республикасы җыелма докладын әзерләү тәртибе турында» 2009 елның 26 мартындагы ПУ-177 номерлы Указын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу察карарга теркәлгән Хисап елы өчен Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен хисап чорына (үткән елга) күрсәткечләрнең ирешелгән мәгънәләре (дәрәҗәләре) һәм аларның планлаштырыла торган мәгънәләре турындагы Татарстан Республикасы Президенты доклады проектын әзерләү регламентын (карарга теркәлә) расларга.

2. Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен (алга таба – федераль күрсәткечләр) үтәү өчен җаваплы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына, кирәк булуга карап, федераль күрсәткечләрне яки аларның декомпозицияләнгән күрсәткечләрен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсенә, илкүләм проектларның төбәккә караган өлешләренә, Татарстан Республикасы дәүләт программаларына һәм (яки) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы һәм Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасындагы Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырыла торган мәгънәләренә ирешү турындагы килешүләргә кертүне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Хисап елы өчен Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләренең ирешелгән мәгънәләре турындагы Татарстан Республикасы Президенты доклады проектын әзерләү регламентын раслау турында» 2008 ел, 25 апрель, 273 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хисап елы өчен Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләренең ирешелгән мәгънәләре турындагы Татарстан Республикасы Президенты доклады проектын әзерләү регламентын раслау хакында» 2008 ел, 25 апрель, 273 нче карарына үзгәрешләр кертү турында» 2008 ел, 6 октябрь, 733 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хисап елы өчен Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләренең ирешелгән мәгънәләре һәм өчьеллык чорга аларның планлаштырыла торган мәгънәләре турындагы Татарстан Республикасы Президенты доклады проектын әзерләү регламентын раслау турында» 2008 ел, 25 апрель, 273 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 24 май, 408 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хисап елы өчен Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләренең ирешелгән мәгънәләре һәм өчьеллык чорга аларның планлаштырыла торган мәгънәләре турындагы Татарстан Республикасы Президенты доклады проектын әзерләү регламентын раслау турында» 2008 ел, 25 апрель, 273 нче карары белән расланган Хисап елы өчен Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләренең ирешелгән мәгънәләре һәм өчьеллык чорга аларның планлаштырыла торган мәгънәләре турындагы Татарстан Республикасы Президенты доклады проектын әзерләү регламентына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 19 октябрь, 826 нчы;

«Хисап елы өчен Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләренең ирешелгән мәгънәләре һәм өчьеллык чорга аларның планлаштырыла торган мәгънәләре турындагы Татарстан Республикасы Президенты доклады проектын әзерләү регламентын раслау турында» 2008 ел, 25 апрель, 273 нче карары белән расланган Хисап елы өчен Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләренең ирешелгән мәгънәләре һәм өчьеллык чорга аларның планлаштырыла торган мәгънәләре турындагы Татарстан Республикасы Президенты доклады проектын әзерләү регламентына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 8 апрель, 270 нче;

«Хисап елы өчен Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләренең ирешелгән мәгънәләре һәм өчьеллык чорга аларның планлаштырыла торган мәгънәләре турындагы Татарстан Республикасы Президенты доклады проектын әзерләү регламентын раслау турында» 2008 ел, 25 апрель, 273 нче карары белән расланган Хисап елы өчен Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләренең ирешелгән мәгънәләре һәм өчьеллык чорга аларның планлаштырыла торган мәгънәләре турындагы Татарстан Республикасы Президенты доклады проектын әзерләү регламентына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 10 май, 371 нче;

«Хисап елы өчен Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләренең ирешелгән мәгънәләре һәм өчьеллык чорга аларның планлаштырыла торган мәгънәләре турындагы Татарстан Республикасы Президенты доклады проектын әзерләү регламентын раслау турында» 2008 ел, 25 апрель, 273 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 9 апрель, 243 нче.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 27 декабрь, 1223 нче
карары белән расланды

Хисап елы өчен Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен хисап чорына (үткән елга) күрсәткечләрнең ирешелгән мәгънәләре (дәрәҗәләре) һәм аларның планлаштырыла торган мәгънәләре турындагы Татарстан Республикасы Президенты докладын проектын әзерләү регламенты

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Регламент хисап елы өчен Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен хисап чорына (үткән елга) күрсәткечләрнең ирешелгән мәгънәләре (дәрәҗәләре) һәм аларның планлаштырыла торган мәгънәләре турындагы Татарстан Республикасы Президенты доклады проектына (алга таба – Доклад проекты) мәгълүмат әзерләү барышында Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) хезмәттәшлеген оештыруны тәэмин итү максатларында эшләнде.

1.2. Бу Регламент Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2019 елның 25 апрелендәге 193 номерлы Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен исәпләү методикаларын раслау турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым актлары үз көчен югалткан дип тану хакында» 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карары, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының хисап елында эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү өчен ирешелгән күрсәткечләр дәрәҗәсе һәм өчъеллык чорга аларның планлаштырылучы дәрәҗәләре турында Татарстан Республикасы Президенты докладын һәм Татарстан Республикасы шәһәр округларының һәм муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген мониторинглау йомгаклары хакында Татарстан Республикасы җыелма

докладын әзерләү тәртибе турында» 2009 елның 26 мартындагы ПУ-177 номерлы Указы нигезендә эшләнде.

1.3. Доклад проектын әзерләү эшләре координаторы (алга таба – Координатор) булып Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тора.

1.4. Доклад проекты өчен мәгълүмат әзерләүдә катнашучылар – Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары (алга таба – Катнашучылар).

1.5. Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты (алга таба – Комитет) ел саен «Ачык Татарстан» мәгълүмат порталының «Ведомстволар хисаплары» бердәм дәүләт хисаплылык системасында (алга таба – Система) мониторинг үткәрүне гамәлгә ашыра.

1.6. Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләре (алга таба – федераль күрсәткечләр) исемлеге һәм аларны Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына беркетү бу Регламентка теркәлгән 1 нче кушымтада китерелгән.

1.7. Федераль күрсәткечнең мәгънәсенә йогынты ясый торган декомпозицияләнгән күрсәткечләр исемлеге Татарстан Республикасының төбәк проектларын һәм дәүләт программаларын тормышка ашыру нәтиҗәләренә бәйле рәвештә үзгәрергә мөмкин, шулай ук аларның иң чик мәгънәләре үзгәрергә мөмкин.

## II. Доклад проекты өчен Координаторның һәм Катнашучыларның мәгълүмат әзерләү вәкаләтләре

2.1. Координатор түбәндәгеләрне тәэмин итә:

Катнашучылар тәкъдимнәре буенча федераль күрсәткечләрне һәм федераль күрсәткеч мәгънәсенә йогынты ясый торган декомпозицияләнгән күрсәткечләрне Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына беркетү турында тәкъдимнәр әзерләүне;

федераль күрсәткечләр буенча җаваплылык үзәкләре булган Катнашучылар тарафыннан кертелгән федераль күрсәткечләргә һәм федераль күрсәткеч мәгънәсенә йогынты ясый торган декомпозицияләнгән күрсәткечләр буенча җыелма мәгълүмат җыюны, гомумиләштерүне һәм формалаштыруны;

Докладның гомумиләштерелгән проектын карап тикшерү һәм федераль күрсәткечләрне килештерү буенча Катнашучылар белән киңәшмәләр үткәрүне;

Доклад проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертүне.

2.2. Федераль күрсәткечләр буенча җаваплылык үзәкләре булган катнашучылар:

илкүләм проектларның төбәккә караган өлешләре һәм Татарстан Республикасы дәүләт программаларының функциональ бәйләнгән күрсәткечләре белән үзара бәйләнештә федераль күрсәткечләрне декомпозицияләүне гамәлгә ашыра;

федераль күрсәткечләрнең декомпозициясен Координатор һәм «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икъти-

садый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән килештерүне тәэмин итә;

федераль күрсәткечләр һәм федераль күрсәткечләрнең мәгънәләренә йогынты ясый торган декомпозицияләнгән күрсәткечләр мәгънәләрен җыюны һәм анализлауны гамәлгә ашыра;

алдан алынган нәтиҗәләрне Координатор белән килештерүне тәэмин итә;

аларга беркетелгән федераль күрсәткечләрнең килештерелгән мәгънәләрен Системага бу Регламентка теркәлгән 1 нче кушымтада күрсәтелгән вакытларда кертүне гамәлгә ашыра;

Доклад проектын формалаштыру өчен федераль күрсәткечләрнең хисап елында ирешелгән һәм планлаштырыла торган мәгънәләре турындагы мәгълүматны Координаторга бу Регламентның 3.1 нче пунктында билгеләнгән вакытларда кертә.

2.3. Комитет түбәндәгеләрне тәэмин итә:

статистика мәгълүматларының факттагы күрсәткечләрен Системага бу Регламентка теркәлгән 1 нче кушымтада күрсәтелгән вакытларда кертүне һәм мониторинг составын һәм визуализацияләүне Системаның тиешле функционаллары ярдәмендә актуаль халәттә тотуны;

Системада Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең җаваплы башкарма органнары тарафыннан федераль күрсәткечләрнең факттагы мәгънәләрен үз вакытында актуальләштерүне тикшерүдә тотуны һәм координацияләүне.

## III. Федераль күрсәткечләр буенча мәгълүмат бирү тәртибе

3.1. Федераль күрсәткечләр буенча җаваплылык үзәкләре булган катнашучылар:

федераль күрсәткечләр буенча җаваплылык үзәге булып торган федераль күрсәткечләрнең хисап елында ирешелгән һәм планлаштырыла торган мәгънәләре турындагы мәгълүматны хисап елыннан соң килә торган елның 10 мартына кадәр бу Регламентка теркәлгән 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча Координаторга кертә;

хисап елыннан соң килә торган елның 10 мартына кадәр федераль күрсәткечләрнең Координатор белән килештерелгән факттагы мәгънәләрен Системага кертүне гамәлгә ашыра.

Мәгънәләрне Системага керткән һәм Координаторга хисап биргән көнгә федераль күрсәткечләр буенча факттагы мәгънәләр булмаган очракта, Доклад проектын формалаштыру өчен Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органының якынча мәгълүматлары яки федераль күрсәткечләр буенча җаваплылык үзәге булып торган Катнашучының бәяләве буенча мәгълүматлар кулланыла; алга таба факттагы мәгънәләрне бу Регламентка теркәлгән 1 нче кушымтада күрсәтелгән вакытлар нигезендә кертү гамәлгә ашырыла, шул ук вакытта төзәтмәләр кертелгән хисапны бастырып чыгару кирәклеге турында Координаторга һәм Комитетка хәбәр ителә.

3.2. Комитет ел саен, хисап елыннан соң килә торган елның 15 мартына кадәр, мониторинг нәтиҗәләре хисапларын Системада бастырып чыгаруны, факттагы

мәгънәләр булганда аларны бу Регламентка теркәлгән 1 нче кушымтада күрсәтелгән вакытлар нигезендә алга таба бастыруны гамәлгә ашыра.

3.3. Координатор Доклад проектын хисап мартыннан соң килә торган 20 мартка кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертә.

3.4. Доклад проектына өстәмә күрсәткечләр кертелгәндә Координаторга мәгълүмат кертү өчен җаваплы үзәк һәм үтәүчеләр Координатор тарафыннан билгеләнә.

Хисап елы өчен Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен хисап чорына (үткән елга) күрсәткечләрнең ирешелгән мәгънәләре (дәрәҗәләре) һәм аларның планлаштырыла торган мәгънәләре турындагы Татарстан Республикасы Президенты доклады проектын әзерләү регламентына
1 нче кушымта

Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләр исемлеге аларны Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына беркетү

| Т/с | Федераль күрсәткеч* исеме, үлчәү берәмлеге | Хисап елы өчен Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен хисап чорына (үткән елга) күрсәткечләрнең ирешелгән мәгънәләре (дәрәҗәләре) һәм аларның планлаштырыла торган мәгънәләре турындагы Татарстан Республикасы Президенты доклады проектына кертү өчен мәгълүмат бирүгә һәм федераль күрсәткечне үтәүгә җаваплылык үзеге / үтәүчеләр | Күрсәткечнең дәвамлылыгы («Ачык Татарстан мәгълүмат порталы ведомстволары хисаплары» бердәм дәүләт хисаплылык системасында мәгълүматлар урнаштыру вакытлары) | Федераль дәрәҗәдә күрсәткечләр мәгънәләре буенча мәгълүмат бирүче федераль башкарма хакимият органы (оешма) |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Хакимияткә (Россия Федерациясе Президентына, Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | ел саен | Россия Федерациясе Федераль саклау хезмәте |

* Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткеч.

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | затларына (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләренә) ышаныч дәрәҗәсе, процент | | | |
| 2. | Икътисадның бюджеттан тыш секторында югары җитештерүчәнлекле эш урыннары саны, мең кеше | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы / Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы (алга таба – Татарстанстат) (килешү буенча) | ел саен (башлангыч мәгълүматлар – хисап елыннан соң килә торган елның 10 мартына кадәр, факт – хисап елыннан соң килә торган елның 23 апреленә кадәр) | Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы, Федераль дәүләт статистикасы хезмәте (алга таба – Росстат) |
| 3. | Кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә эшләүчеләр (индивидуаль эшмәкәрләрне кертеп) саны, мең кеше | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы / Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | ел саен (башлангыч мәгълүматлар – хисап елыннан соң килә торган елның 10 мартына кадәр, факт – хисап елыннан соң килә торган елның 10 августына кадәр) | Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы |
| 4. | Икътисадның чимал булмаган база тармакларында хезмәт җитештерүчәнлеге, процент (2017 ел – база мәгънәсе) | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы / Татарстан Республикасы Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен | ел саен (башлангыч мәгълүматлар – хисап елыннан соң килә торган елның 10 мартына кадәр, факт – | Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы, Росстат |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, Татарстанстат (килешү буенча) | хисап елыннан соң килә торган елның 23 апреленә кадәр) | |
| 5. | Реаль уртача айлык эш хакы дәрәҗәсе (2017 ел – төп мәгънәсе), процент | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы / Татарстанстат (килешү буенча), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | ел саен (башлангыч мәгълүматлар – хисап елыннан соң килә торган елның 10 марты-на кадәр, факт – хисап елыннан соң килә торган елның 23 апреленә кадәр) | Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы, Росстат |
| 6. | Төп капиталга инвестицияләр күләме (инфраструктура монопо-лияләре инвестицияләре (федераль проектлар) һәм федераль бюджет-ның бюджет ассигнованиеләреннән тыш) процент (2018 ел – төп мәгънәсе) | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы / Татарстанстат (килешү буенча), Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы, Татарстан Республикасы Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | ел саен (башлангыч мәгълүматлар – хисап елыннан соң килә торган елның 10 мартына кадәр, факт – хисап елыннан соң килә торган елның 23 апреленә кадәр) | Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы, Росстат |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 7. | Фәкыйрьлек дәрәҗәсе, процент | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы / Татарстанстат (килешү буенча), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | ел саен (башлангыч мәгълүматлар – хисап елыннан соң килә торган елның 10 мартына кадәр, факт – хисап елыннан соң килә торган елның 16 маена кадәр) | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы, Росстат |
| 8. | Туганда көтелә торган гомер озынлыгы, яшь | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы / Татарстанстат (килешү буенча) | ел саен (башлангыч мәгълүматлар – хисап елыннан соң килә торган елның 10 мартына кадәр, факт – хисап елыннан соң килә торган елның 23 апреленә кадәр) | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы, Росстат |
| 9. | Халыкның табигый артуы, 1 мең кешегә | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы / Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Граждан хәле актларын язу идарәсе, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстанстат (килешү буенча), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | ел саен (башлангыч мәгълүматлар – хисап елыннан соң килә торган елның 10 мартына кадәр, факт – хисап елыннан соң килә торган елның 23 апреленә кадәр) | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы, Росстат |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 10. | Торак шартларын яхшырткан гаилә-ләр саны, мең гаилә | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы / Татарстанстат (килешү буенча), Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | ел саен (башлангыч мәгълүматлар – хисап елыннан соң килә торган елның 10 мартына кадәр, факт – хисап елыннан соң килә торган елның 1 апреленә кадәр) | Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| 11. | Торакның һәркем алырлык булу дәрәҗәсе, процент | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы / Татарстанстат (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | ел саен (башлангыч мәгъ-лүматлар – хисап елыннан соң килә торган елның 10 мартына кадәр, факт – хисап елыннан соң килә торган елның 1 апреленә кадәр) | Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| 12. | Уңайлы шәһәр мохите булган шәһәрләр өлеше, процент | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы / Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Татарстанстат (килешү буенча), Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча), Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (Татарстан) (килешү буенча) | ел саен (башлангыч мәгъ-лүматлар – хисап елыннан соң килә торган елның 10 мартына кадәр, факт – хисап елыннан соң килә торган елның 20 февраленә кадәр) | Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 13. | Әйләнә-тирә мохитнең сыйфаты, процент | Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы / Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | ел саен (башлангыч мәгъ-лүматлар – хисап елыннан соң килә торган елның 10 мартына кадәр, факт – хисап елыннан соң килә торган елның 10 маена кадәр) | Россия Федерациясе Табигый байлыклар һәм экология министр-лыгы |
| 14. | Белем бирү дәрәҗәсе, процент | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы / Татарстанстат (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | ел саен (башлангыч мәгъ-лүматлар – хисап елыннан соң килә торган елның 10 мартына кадәр, факт – хисап елыннан соң килә торган елның 23 апреленә кадәр) | Россия Федерациясе Мәгариф министр-лыгы, Росстат |
| 15. | Норматив таләпләргә туры килә торган төбәк әһәмиятендәге автомо-биль юллары һәм шәһәр агломера-цияләрендәге автомобиль юллары өлеше (йөкләнешне исәпкә алып), процент | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы / Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | ел саен (башлангыч мәгъ-лүматлар – хисап елыннан соң килә торган елның 10 мартына кадәр, факт – хисап елыннан соң килә торган елның 1 мартына кадәр) | Россия Федерациясе Транспорт министр-лыгы |

Хисап елы өчен Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен хисап чорына (үткән елга) күрсәткечләрнең ирешелгән мәгънәләре (дәрәҗәләре) һәм аларның планлаштырыла торган мәгънәләре турындагы Татарстан Республикасы Президенты доклады проектын әзерләү регламентына 2 нче кушымта

Форма

Хисап елы өчен Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләре һәм аларның планлаштырыла торган мәгънәләре

________________________________________________
(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы исеме)

| Т/с | Күрсәткеч исеме, үлчәү берәмлеге | Күрсәткечнең факттагы мәгънәләре | | | Фараз | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | (n - 2) ел | (n - 1) ел | (n) ел | (n + 1) ел | (n + 2) ел | (n + …) ел |
| 1. | | | | | | | |
| ... | | | | | | | |

____________________________